КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 май г.Казань № 415

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 18 май, 196 нчы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 18 май, 196 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 5 октябрь, 533 нче; 2009 ел, 2 март, 120 нче; 2009 ел, 16 июль, 498 нче; 2010 ел, 21 июнь, 494 нче; 2013 ел, 29 гыйнвар, 41 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 883 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең кыйммәте, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча тиешле бүлекләре, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән килештереп, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин